**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «7» июленнән № 24-190

2021 елда «2020-2022 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасы чараларын тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Р. Х. Габетдиновның «2021 елда «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасы чараларын тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында»гы мәгълүматын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «2021 елда «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль максатчан программасы чараларын тормышка ашыруның барышы һәм 2022 елга бурычлар турында»гы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

- пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә кагыйдәләрне үтәүне контрольдә тотуны көчәйтергә;

- билгеләнгән таләпләр нигезендә җәяүлеләр кичү юлларын төзекләндерергә, шул исәптән торак пунктларда җәяүлеләр кичү юлларын ясалма яктырту белән җиһазландырырга, шулай ук җайга салына торган җәяүлеләр кичү урыннарында Т7 тибындагы светодиод светофорлар урнаштырырга;

- торак йортлар төзегәндә бер фатирга бер машина урыны исәбеннән автомобильләр өчен парковка урыннары санын исәпкә алырга;

- каты өслекле юлларның сыйфатын яхшырту һәм санын арттыру буенча эшне активлаштырырга;

- транспорт чаралары һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру системасын контрольдә тоту;

- кисәтүче юл билгеләрен кую буенча эшне активлаштырырга.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе бүлегенә тәкъдим итәргә:

- юлларны һәм юл корылмаларын караганда кагыйдәләрне, нормативларны һәм стандартларны үтәүне контрольдә тотуны көчәйтергә;

- җәяүлеләрнең иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашырырга.

4. «Яңа Чишмә РҮХ» ДАССОсына юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә үз вакытында сыйфатлы ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре Башкарма комитетларына торак пунктлар эчендә юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларын үтәү буенча эшне активлаштырырга тәкъдим итәргә.

6. 3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов